# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Җирле үзидарә органнары эшчәнлеген камилләштерүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2010 елның 8 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

"Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 7 (II өлеш); 2005, № 2, № 4 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 11; 2006, № 4, № 7 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш), № 8; 2008, № 1, № 12 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 7 статьяда:

а) 3 өлештә "кимрәк" сүзен "артык булмаган" сүзләренә алмаштырырга;

б) 4 өлешкә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: "Муниципаль берәмлек уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль хокукый акт проекты буенча тәкъдимнәрне исәпкә алу тәртибен, шулай ук, күрсәтелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр муниципаль берәмлек уставын Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга туры китерү максатында кертелгән очракта, аның буенча фикер алышуда гражданнарның катнашу тәртибен рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) таләп ителми.";

в) 8 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"8. Муниципаль берәмлек уставына кертелгән һәм җирле үзидарә органнарының структурасын, җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен (җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затлары вәкаләтләреннән, вәкаләтләр чорыннан һәм сайлану тәртибеннән тыш) үзгәртүче үзгәрешләр һәм өстәмәләр уставка

күрсәтелгән үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертү турында муниципаль хокукый акт кабул иткән муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы вәкаләтләре чоры тәмамланганнан соң үз көченә керә.

Муниципаль берәмлек уставына кертелгән һәм муниципаль берәмлекнең контроль органын булдыруны күздә тотучы үзгәрешләр һәм өстәмәләр әлеге статьяның 7 өлешендә каралган тәртиптә үз көченә керә.";

2) 9 статьяның 2 өлешендә "Коммерциягә карамаган оешмалар турында" Федераль законның" сүзләрен "Коммерциягә карамаган оешмалар турында" 1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба – "Коммерциягә карамаган оешмалар турында" Федераль закон)" сүзләренә алмаштырырга;

3) 15 статьяның 1 өлешендә:

а) 21 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"21) торак пунктларда урамнарга, мәйданнарга һәм гражданнар яши торган башка территорияләргә исемнәр бирү, йортларның тәртип санын билгеләү, урамнарны яктыртуны һәм урамнар исемнәре, йортлар номерлары белән күрсәткечләр урнаштыруны оештыру;";

б) түбәндәге эчтәлекле 34 пункт өстәргә:

"34) "Коммерциягә карамаган оешмалар турында" Федераль законның $31^1$ һәм $31^3$ статьяларында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә коммерциягә карамаган социаль юнәлештәге оешмаларга ярдәм күрсәтү.";

4) $15^1$ статьяда:

а) 1 өлештә:

2 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

түбәндәге эчтәлекле $8^1$ пункт өстәргә:

"$8^1$) янгынга каршы муниципаль хезмәт булдыруга;";

б) 2 өлештә "бары тик җирле бюджетларның үз керемнәре исәбеннән генә хәл итәргә хокуклы (федераль бюджеттан һәм Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган субвенцияләрдән һәм дотацияләрдән гайре)" сүзләрен "Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларыннан бирелгән бюджетара трансфертлардан тыш, җирле бюджетлар керемнәре һәм өстәмә норматив исәпләүләр буенча салым керемнәре акчалары исәбеннән хәл итәргә хокуклы" сүзләренә алмаштырырга;

5) 16 статьяда:

а) 1 өлешнең 25 пунктында "үстерүгә" сүзеннән соң ", коммерциягә карамаган социаль юнәлештәге оешмаларга, хәйрия эшчәнлегенә һәм ихтыяр белдерүгә" сүзләрен өстәргә;

б) 2 өлештә "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" Федераль закон нигезендә муниципаль берәмлекләр булмаган торак пунктларда" сүзләрен төшереп калдырырга;

в) 4 өлешнең беренче абзацында "субвенцияләр" сүзен "бюджетара трансфертлар" сүзләренә алмаштырырга, "муниципаль район бюджетына" сүзләреннән соң "Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә" сүзләрен өстәргә;

г) 4 өлешнең икенче абзацында "субвенцияләр" сүзен "бюджетара трансфертлар" сүзләренә алмаштырырга, "тиешле торак пунктлар бюджетларына" сүзләреннән соң "Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә" сүзләрен өстәргә;

д) 4 өлешнең өченче абзацында "субвенцияләрнең" сүзен "әлеге өлештә күрсәтелгән бюджетара трансфертларның" сүзләренә алмаштырырга;

6) $16^1$ статьяда:

а) 1 өлешнең 2 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

б) 2 өлештә "бары тик җирле бюджетларның үз керемнәре исәбеннән генә хәл итәргә хокуклы (федераль бюджеттан һәм Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган субвенцияләрдән һәм дотацияләрдән гайре)" сүзләрен "Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларыннан бирелә торган бюджетара трансфертлардан тыш, җирле бюджетлар керемнәре һәм өстәмә норматив исәпләүләр буенча салым керемнәре акчалары исәбеннән хәл итәргә хокуклы" сүзләренә алмаштырырга;

7) 17 статьяның 1 өлешендә:

а) 27 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"27) шәһәр округындагы урамнарга, мәйданнарга һәм гражданнар яши торган башка территорияләргә исемнәр бирү, йортларның тәртип санын билгеләү, урамнарны яктыртуны һәм урамнар исемнәре, йортлар номерлары белән күрсәткечләр урнаштыруны оештыру;";

б) 33 пунктта "үсешенә" сүзеннән соң ", коммерциягә карамаган социаль юнәлештәге оешмаларга, хәйрия эшчәнлегенә һәм ихтыяр белдерүгә" сүзләрен өстәргә;

8) $17^1$ статьяда:

а) 1 өлештә:

2 пунктны үз көчен югалткан дип танырга:

түбәндәге эчтәлекле $8^1$ өстәргә:

"$8^1$) янгынга каршы муниципаль хезмәт булдыруга;";

б) 2 өлештә "бары тик җирле бюджетларның үз керемнәре исәбеннән генә хәл итәргә хокуклы (федераль бюджеттан һәм Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган субвенцияләрдән һәм дотацияләрдән гайре)" сүзләрен "Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларыннан бирелгән бюджетара трансфертлардан тыш, җирле бюджетлар керемнәре һәм өстәмә норматив исәпләүләр буенча салым керемнәре акчалары исәбеннән хәл итәргә хокуклы" сүзләренә алмаштырырга;

9) 18 статьяның 1 өлешендә:

а) 3 пунктта "муниципаль учреждениеләрне финанслау," сүзләрен "муниципаль казна учреждениеләре эшчәнлеген финанс ягыннан тәэмин итүне һәм бюджет һәм автоном муниципаль учреждениеләрнең муниципаль йөкләмәне үтәвен финанс ягыннан тәэмин итүне гамәлгә ашыру, шулай ук" сүзләренә алмаштырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле $8^2$ пункт өстәргә:

"$8^2$) энергияне сак тоту һәм энергиянең нәтиҗәлелеген арттыру өлкәсендә муниципаль программаларны раслау һәм гамәлгә ашыру, биналары муниципаль торак фондын тәшкил итә торган күпфатирлы йортларда муниципаль берәмлек чикләрендә энергетик тикшерү оештыру, энергияне сак тоту турындагы һәм энергиянең нәтиҗәлелеген арттыру турындагы законнарда каралган башка чараларны оештыру һәм үткәрү;";

10) 21 статьяның 9 өлешендә "органнарын тоту чыгымнарын финанслау" сүзләрен "органнары эшчәнлеген финанс ягыннан тәэмин итү" сүзләренә алмаштырырга;

11) 22 статьяда:

а) 2 өлешнең икенче абзацында "кимрәк булса" сүзләрен "артык булмаса" сүзләренә алмаштырырга;

б) 8 өлешнең 6 пунктында "һәм учреждениеләр төзү" сүзләрен "төзү" сүзенә алмаштырырга;

в) 10 өлештә "башлыгы булып торса" сүзләрен "башлык вәкаләтләрен башкарса" сүзләренә алмаштырырга;

г) 11 өлештә ", муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органының норматив характерга ия булмаган карарларын имзалый" сүзләрен өстәргә;

12) 23 статьяда:

а) 1 өлешкә "оештыру мәсьәләләре" сүзләреннән соң "һәм федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары, муниципаль берәмлек уставы белән үз компетенциясенә кертелгән башка мәсьәләләр буенча" сүзләрен өстәргә;

б) 5 өлешнең беренче җөмләсендә "хокукый акт" сүзләреннән соң "10 көн эчендә" сүзләрен өстәргә, икенче җөмләсендә "башлыгы булып торган" сүзләрен "башлыгы вәкаләтләрен башкара торган" сүзләренә алмаштырырга;

13) 24 статьяның 6 өлешендә "рәисе булып торса" сүзләрен "рәисе вәкаләтләрен башкарса" сүзләренә, "башлыгы булса" сүзләрен "башлыгы вәкаләтләрен башкарса" сүзләренә алмаштырырга;

14) 26 статьяда:

а) 1 өлештә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

"Җирле администрация башлыгы белән контракт җирле администрация башлыгы вазыйфасына затны билгеләп кую турында карар кабул иткән муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы вәкаләтләре чорына (яңа чакырылыш муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы эше башланган көнгә кадәр), ләкин кимендә ике елга төзелә.";

б) 7 өлештә:

1 пунктта "шартлары бозылуга" сүзләреннән соң ", шулай ук "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" Федераль законда билгеләнгән чикләүләрне үтәмәүгә" сүзләрен өстәргә;

2 пунктта "шартлары бозылуга" сүзләреннән соң ", шулай ук "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" Федераль законда билгеләнгән чикләүләрне үтәмәүгә" сүзләрен өстәргә;

15) 34 статьяның 1 өлешендәге 7 пунктта "муниципаль учреждениеләрнең" сүзләрен "муниципаль казна учреждениеләренең" сүзләренә алмаштырырга;

16) 42 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"42 статья. **Муниципаль берәмлекләрнең предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар төзүгә хокукы**

Муниципаль берәмлекләр муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләр төзергә, хуҗалык җәмгыятьләре, шул исәптән җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле муниципальара хуҗалык җәмгыятьләре, булдыруда катнашырга мөмкин. Муниципаль предприятиеләргә һәм учреждениеләргә карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен җирле үзидарәнең вәкаләтле органнары гамәлгә ашыра.";

17) 43 статьяда:

а) 1 өлештә җөмлә башына "Гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкаручы" сүзләрен өстәргә;

б) 2 өлештә "учреждениеләр" сүзен "казна учреждениеләре" сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

"Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт турында" 2008 елның 17 гыйнварындагы 5-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 1, № 7 (I өлеш), № 12 (I өлеш), № 12 (VI өлеш); 2009, № 2, № 7 – 8 (I өлеш); 2010, № 1 – 2), 1 нче кушымтаның 8.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

"8.1. Башкарма комитет җитәкчесе белән контракт башкарма комитет җитәкчесе вазыйфасына затны билгеләп кую турында карар кабул иткән муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы вәкаләтләре чорына (яңа чакырылыш муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы эше башланган көнгә кадәр) төзелә һәм ______ тәшкил итә.".

**3 статья**

Әлеге Закон, үз көченә керүнең шушы статья белән башка сроклары билгеләнгән нигезләмәләреннән тыш, рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Әлеге Законның 1 статьясындагы 9 пунктының "а" пунктчасы, 10 пункты, 11 пунктының "б" пунктчасы, 15, 16 һәм 17 пунктлары 2011 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2010 елның 30 июле
№ 58-ТРЗ